«2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр чорга Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» Апас муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 13 декабрендәге 306 номерлы карары

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьяларына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен раслау турында" 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карарына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләрнең һәм эшләрнең минималь исемлеген раслау турында" туры китереп, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.«2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр чорга Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен раслау турында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 23 декабрендәге 284 номерлы карарына, кушымтадагы 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Йорт эчендәге инженерлык - канализация челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм тоту | аена торак бинаның гомуми мәйданының кв. м. | 2,17 | 2,17 | 2,17 | 2,17 |

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары А. М. Хәсәновка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.М. Хәсәнов